# ӘЙДӘГЕЗ, ТАНЫШ БУЛЫЙК!

**Хәерле көн, дуслар!**
**Исәнмесез!**

**Сәлам белән башлыйм сүземне.**
**Таныштырыйм дип чыгып бастым, ләкин**
**Читен икән мактау үзеңне.**

**Мин Надежда Васильевна булам,**
**Килдем Иске Матак авылыннан.**
**Ел тәрбиячесе бәйгесенә**
**“Кояшкай” бакчасыннан.**

**Гади генә бер кеше мин үзем,**
**Гади түгел ләкин һөнәрем.**
**“Тәрбияче” дигән олы исем йөртәм,**
**Шул исемне аклау - теләгем.**





Табигатьнең гүзәллеген тоя беләм,
Хисләр җылылыгын сабыйларга бирәм.
Һәр нәнине нәфис гөлдәй күрәм,
Шул гөлләргә йомшак сулыш өрәм.



“Кояшкай” бакчасында
Уз хезмәтемне куям.
Эшемне бик яратканга
Эшләве җиңел миңа.

# Балаларга булган мәхәббәтем тәрбиячелек эшемдә миңа зур көч бирә.





Хезмәтемнең сукмагыннан
Барган чакта тиз-тиз атлап.
Гаделлек һәм таләпчәнлек
Йөртә мине һаман саклап.
Җиңел түгел барыр юлдан,
Тиз-тиз генә алга атлап.
Зилзиләләр көтеп тора
Борылышта мине кайчак.
Көтеп тора борылышта
Авырлык та, киртәләр дә.
Шатлыгы да бу тормышта.
Нәтиҗәмне күрим диеп,
Ялгышып та куям кайчак.
Төзәтеп шул хаталарны,
Алга таба атлыйм һәрчак



Тәрбияче һөнәрен төрле кеше төрлечә аңлый. Минемчә, тәрбияче, иң беренче чиратта, бала күңелен аңлый белүче изге йөрәкле, ата-анага төпле киңәш бирүче педагог булса, икенчедән, ул мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле ирекле шәхес формалаштыручы остаз да булырга тиеш.

Һәр тәрбияченең үз язмышын балалар бакчасы белән бәйләве дә төрлечә. Берәүләр балачактан ук үзләрен бу һөнәргә багышлаячакларын тоемлыйлар һәм шуңа омтылалар, әзерләнәләр. Икенчеләр исә балага белем бирү, аны олы тормыш юлына әзерләү кебек изге эшкә очраклы рәвештә кереп китәләр.

Мин үземне шуларның беренчесенә кертер идем. Педагоглар нәселеннән түгел мин, шулай да нишләптер кечкенәдән үк минем хыялым - тәрбияче булу иде.

Менә инде мин – тәрбияче. Балалар бакчасына барыр алдыннан мин балаларымның һәрберсен күз алдымнан үткәрәм, аларның күңел дөньясын ачарга, ышанычларын акларга тырышам. Кәефем нинди булуга карамастан, алар янына ачык күңел белән керәм, чөнки баланың сизгер йөрәген алдый алмыйсың. Аның күңеленә кешелеклелек, игелеклелек орлыклары салырга җыенасың икән, иң беренче чиратта үзең үрнәк булырга тиешсең.

Нинди генә заманда, кайсы гына вакытта эшләмә , тәрбиячеләр алдында зур бурычлар ,яңадан – яңа таләпләр куела . ФГОС программасы белән танышып үткәч, мин яңа стандартларның “Укырга өйрәтү”, “Яшәргә өйрәтү” һәм “Эшләргә өйрәтү”, “Бергә эшләргә өйрәтү” икәнен аңладым. Чөнки яңа стандартлар буенча эшләгәндә балаларның белем дәрәҗәсе бермә-бер үсә, логик яктан фикер йөртергә өйрәнә, максатка ирешергә омтылышы барлыкка килә.

Шушы дүрт этап бер берсе белән бәйләнеп барырга тиеш, шул очракта гына алдыбызга куелган бурычлар камил дәрәҗәгә ирешә ала.

# Мин һәр баланы үз баламдай якын итәм.





Күп еллар буена балалар белән эшләү дәверендә мин бер гыйбәрәне исемнән мәңге чыгармадым: “Тәрбияче – үзе тәрбияле булырга тиеш”. Ә тәрбияле булу – ул зур төшенчә. Алтыннан да кыйммәтле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Ата-ана үзенең йөрәк җимеше – баласын безнең кулларга тапшыра. Мин һәр баланы үз баламдай якын итәм. Аларга “улым”, “кызым” диеп эндәшү баланы миңа тагын да якынайта. Үз балаларыма биреп җиткерә алмаган күңел җылысын аларга бирәм, үз балаларымда күрергә теләгән сыйфатларны аларда булдырырга тырышам.

http://gallery.world/wallpaper/304714.html

# Балаларның сәләтен үстерү, аларны төрле яклап ачу өчен тәрбияче нинди генә шөгыльләр тапмый.















ХАЙВАННАР
Дидактическая игра «Составь узор на салфетке»
ДОМИНО
ХАЙВАННАР








**Әгәр миннән сорасалар,**
**Бәхет – ни ул, дисәләр.**
**Бәхет – минем балаларым**
**Кеше булып үссәләр.**





